РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕМЕТЕСКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Ф.Хусни, 56 А, село Большие Метески, 422082
тел.: (884360) 54-4-40 (факс)
E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

**ОКПО 94318062 ОГРН1061675010430**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**
Ф.Хөсни урамы, 56 А, Олы Мәтәскә авылы, 422082
тел.: (884360) 54 -4-40 (факс)
E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

ИНН/КПП 1619004411/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№5** **09.03.2021г**

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегендә 2022 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы ЛХ-28/418/2022 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегендә 6964,98сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карар 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче М.А.Валиуллин

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә
авыл җирлеге Башкарма комитетының
09.03.2022 ел №5 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегендә 2022 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 135,50 |
| 2.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 2900,14 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 828,72 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3100,32 |
| Барлыгы | 6964,98 |